# Кыямәт көненә ышану

الايمان باليوم الاخر

اللغة التترية

Шәйх Хәйсәм ибн Мөхәммәд Сәрхән

ALSARHAAN.COM

الإيمان باليوم الآخر: ركن من أركان الإيمان.

**Кыямәт көненә ышану иман нигезләренең берсе.**

وقد قرن الله سبحانه الإيمان به بالإيمان باليوم الآخر في تسعة عشر موضعا من كتابه العزيز.

**Аллаһка ышану белән Кыямәт көненә ышануны Аллаһ Үз китабында унтугыз урында бер-берсенә бәйләгән.**

وأكد أن هذا اليوم واقع لا محالة وأنه لا مفر منه ولا محيد عنه.

**Шулай ук шушы көн һичшиксез булачагын, аннан качып булмавын һәм ул котылгысыз икәнен раслаган.**

قال تعالى:

الله لا إله إلا هو ليجمعنكم إلى يوم القيامة لا ريب فيه ومن اصدق من الله حديثا.

**Аллаһ әйтте: «Аллаһтан башка гыйбадәткә лаеклы һичбер зат юк, Ул сезне һичшиксез Кыямәт көнендә җыяр, бу көндә шик-шөбһә юк, һәм кем соң ул Аллаһтан да дөресрәк сөйләүче?»**

ومعنى الإيمان باليوم الآخر التصديق الجازم بوقوع كل ما أخبر الله عنه في كتابه وأخبر به رسوله صلى الله عليه وسلم مما يكون بعد الموت والعمل بمقتضى هذا الاعتقاد

Һәм Кыямәт көненә ышануның мәгънәсе – Аллаһ Үз кибында һәм Пәйгамбәребез ﷺ хәбәр иткән үлемнән соң булачак барлык нәрсәгә дә чын-чынлап иман китерү һәм шушы инанганлык таләп иткән гамәлләрне кылу.

ويدخل في الإيمان باليوم الآخر الإيمان بأمارات الساعة و الإيمان بالموت و الإيمان بما بعد الموت من سؤال القبر وعذابه ونعيمه.

Кыямәт көненә ышану үз эченә аның галәмәтләренә, үлемгә, үлемнән соң буласы кабердәге сораугa, биреләсе җәзага һәм ләззәтләнүгә ышануны ала.

والإيمان بتفاصيل ما جاء في ذلك اليوم من النفخ في الصور.

Шулай ук шушы көндә буласы быргыга өрүгә ышану.

والإيمان بالبعث والنشور

Шулай ук үлгәннән соң терелүгә ышану.

و الإيمان بالحشر وجمع الخلائق في الموقف وأحوالهم فيه.

Мәхлукларның барысының да бер урынга куылып, шунда җыелуларына, һәм аларның нинди хәлатләрдә булуларына ышану.

و الإيمان بلقاء الله عز وجل والعرض والحساب والاقتصاص من الظالم للمظلوم.

Аллаһ Раббыбыз белән очрашуга, Аны күрүгә, исәп-хисапка, золымлык кылучыга карата золымлык кичерүчесенең җавап җәзасына ышану.

والايمان بنشر صحائف الأعمال فآخذٌ كتابه بيمينه وآخذٌ كتابه بشماله.

Гамәл дәфтәрләренең таратылуына, аларны яки уң кулга, яки сул кулга бирелүенә ышану.

الإيمان بالميزان والصراط وحوض نبينا محمد صلى الله عليه وسلم والشفاعة والجنة والنار.

**Үлчәүгә, сырат күперенә, Пәйгамбәребезнең ﷺ сулыгына, аның шәфәгатенә, Җәннәткә һәм Җәһәннәмгә ышану.**

وإذا تحقق هذا الإيمان في قلب العبد أثمر له ثمرات عظيمة منها:

**Һәм әгәр шушы нәрсәләргә иман кешенең йөрәгендә хаклык булып беркелсә, моның нәтиҗәләре бик зур булыр, шулардан:**

الرغبة في فعل الطاعات والحرص عليها رجاء ثواب ذلك اليوم.

**Шушы көннең әҗер-савабына өметләнеп, буйсыну гамәлләрен һәм аларга ашкынуны теләү.**

الرهبة من فعل المعصية أو الرضا بها خوفا من عقاب ذلك اليوم.

**Шушы көннең газабыннан куркып, гөнаһлы гамәлләрне кылудан яки алар белән риза булудан курку.**

تسليةُ المؤمن عما يفوته من النعيم في الدنيا بما يرجوه من نعيم الآخرة وثوابها.

**Мөэминнең ахырәттәге ләззәтләргә өмет итеп бу дөнья ләззәтләрен калдыру юанычы.**

الإيمان بالآخرة يُفيض السلام والسكينة على روح المؤمن وشعوره.

ويبعد عنه القلق والسخط والقنوط.

**Ахирәткә ышану мөэминнең күңеленә тынычлык һәм иминлек хисләрен сала. Һәм аннан тынгысызлык, ачу һәм рухи төшенкелекне ерагайта.**

الإيمان بالآخرة حارس للقيم الأخلاقية، وحاجز دون الاندفاع في الصراع المحموم على متاع الدنيا.

Кыямәт көненә ышану – әхлак байлыгын саклаучы һәм дөнья ләззәтләренә ашкынып шашынулы көрәштән тоткарлык.

فإذا علم العبد أن ذاك اليوم آتٍ لا ريب فيه كان عليه أن يُعدَّ العدة ويشمر عن ساعد الجد استعدادا له.

Һәм әгәр кеше бер шиксез шушы көннең киләсен белсә, ул бар көчен куеп шушы көнгә әзерләнергә тиеш.

قال تعالى:

يا أيها الذين آمنوا اتقوا الله ولتنظر نفس ماقدمت لغد واتقوا الله إن الله خبير بما تعملون.

Аллаһ әйтте: «Әй сез иман китерүчеләр, Аллаһтан куркыгыз, һәм һәрбер җан иртәгәсе көнгә нәрсә әзерләп куйганына карасын. Шулай булгач, Аллаһтан куркыгыз, хакыйкатьтә, Аллаһ сез нәрсә кылганыгызны хәбәрдар».